КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 март г.Казань № 123

Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча экспериментта Татарстан Республикасының катнашуы турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча эксперимент үткәрү турында» 2020 елның 31 декабрендәге 2429 номерлы карары нигезендә, дәүләт мәгълүмат ресурсларындагы җир һәм күчемсез мөлкәт объектлары турындагы мәгълүматларның сыйфатын тәэмин итү һәм аларны интеграцияләү, шулай ук Татарстан Республикасында җир-мөлкәт комплексыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча экспериментта (алга таба – Эксперимент) Татарстан Республикасының катнашуы турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинны Татарстан Республикасы территориясендә Эксперимент үткәрү һәм Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте, аның Татарстан Республикасындагы территориаль органы, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча эксперимент үткәрү турында» 2020 елның 31 декабрендәге 2429 номерлы карары белән билгеләнгән Экспериментта катнашучылар белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү өчен җаваплы итеп билгеләргә, аңа Экспериментны тормышка ашыру өчен кирәкле чараларны координацияләү буенча ведомствоара эшче төркем эшендә катнашуга, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте белән Эксперимент үткәрү кысаларында үзара хезмәттәшлек итү турында, үз эченә шулай ук мәгълүмати хезмәттәшлекне алган килешү төзүгә вәкаләт бирергә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын Татарстан Республикасы исеменнән Экспериментта катнашуга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасында Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча эксперимент үткәрүнең оператив штабын төзергә һәм аның составын (карарга теркәлә) расларга.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 30 көн эчендә Экспериментта кулланыла торган төбәк мәгълүмат системалары һәм ресурслары исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә һәм «Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын тулыландыру өчен төбәк мәгълүмат системаларыннан мәгълүмат җибәрүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 30 көн эчендә:

Татарстан Республикасының Әтнә, Зеленодольск һәм Питрәч муниципаль районнары территориясендә 2021 елда чараларны өстенлекле гамәлгә ашыру максатларында «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын тулыландыру» проекты чараларын тормышка ашыру буенча «юл картасына» үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Эксперимент үткәрү буенча оператив штаб турында нигезләмә эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

7. Татарстан Республикасы Әтнә, Зеленодольск һәм Питрәч муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына Экспериментта катнашуны тәкъдим итәргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021ел, 12 март, 123 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында
Җир һәм күчемсез мөлкәт турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча эксперимент үткәрүнең оператив штабы
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, оператив штаб рәисе |
| Хөснетдинов Таһир Фәрхәт улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары вазыйфаларын башкаручы, оператив штаб рәисе урынбасары |

Оператив штаб әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Афанасьев Михаил Павлович | Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Гущин Иван Николаевич | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе |
| Зарипов Илгизәр Наил улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары |
| Кашапов Илһам Миңнехан улы | Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Комаров Руслан Викторович | «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Костин Артём Петрович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Мерзакриев Рөстәм Рәүф улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Мөгыйнов Азат Рөстәм улы | «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |
| Начвин Илья Сергеевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары |
| Самойлов Антон Витальевич | «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Тарнавский Егор Александрович | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары |
| Хәбипов Ришат Рәшит улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары |
| Хәкимов Габделәхәт Гыйлемхан улы | Татарстан Республикасының Әтнә муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Фәттерахманов Ленар Рифат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы |
| Чукин Артем Викторович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Шәрәфетдинов Рамил Гомәр улы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары. |